


# Рәхмәт сиңа, Әлифбам!

*Әлифба,Әлифба, беренче битеңне*
*Ачкан көн хәтердә - зур бәйрәм шикелле.*
*Иң якын дустыбыз булдың син гел безнең,*
*Һәр хәреф елмаеп әйтте үз исемен :*
*Һәм алар бик матур сүзләргә әйләнде,*
*Сүз төзеп укуы кызыклы,күңелле.*
*Әлифба,әлифба, китәсең бит инде,*
*Җыр итеп җырлыйбыз, иң соңгы битеңне.*

# Туган телем

1. Балам диеп туган телдә
Эндәшә миңа әткәм.
Әнием дип әнкәемә
Мин туган телдә дәшәм.
Кушымта.
**Дөньяда иң матур ил**
**Ул минем туган илем.**
**Дөньяда иң матур тел**
**Ул минем туган телем.**

2. Туган телемдә сөйләшеп
Яшим мин туган илдә.
Туган ил дигән сүзне дә
Әйтәм мин туган телдә.
Кушымта.

3. Иң изге хисләремне
Туган телдә аңлатам.
Шуңа күрә туган телне
Хөрмәтлим мин, яратам
Кушымта.


А Ә И Л Ы У Д Ү О Т
Н Ө М Б Е Ё П К Г Ф
Р Э З С Й В Я Ш Ю
Х Һ Ч Җ Ж Ц Щ Ь Ъ
art16.ru

# Әлифба

1. И, Әлифба, син тәүге фәннәрнең
   Тәүге баскычы.
   Син кадерле, син туган телемнең
   Алтын ачкычы.
   Кушымта.
   **Укырга да өйрәттең,**
   **Язарга да өйрәттең.**
   **Син кадерле, син туган телемнең**
   **Алтын ачкычы.**

2. И, Әлифбам, син кулымда балкыйсың
   Нәкъ нур булып.
   Һәр баланы зур бәхеткә илтүче
   Ак юл булып.
   Кушымта.
   **Укырга да өйрәттең,**
   **Язарга да өйрәттең.**
   **Син кадерле, син туган телемнең**
   **Алтын ачкычы.**




effects1.ru

# Өйрәтәләр мәктәпләрдә

1. ***Каләм тотып кулларга,***
   ***Хәрефләрне тезәргә.***
   ***Өйрәтәләр мәктәпләрдә, мәктәпләрдә***
   ***Тапкырларга, бүләргә,***
   ***Нәниләрне сөяргә.***
   ***Өйрәтәләр мәктәпләрдә, мәктәпләрдә***
   ***Тапкырларга, бүләргә,***
   ***Нәниләрне сөяргә.***
   ***Өйрәтәләр мәктәпләрдә, мәктәпләрдә***

***2. Бишне бишкә кушарга,***
***Иҗектән сүз ясарга.***
***Өйрәтәләр мәктәпләрдә, мәктәпләрдә***
***Белер өчен бик күпне,***
***Яратырга китапны.***
***Өйрәтәләр мәктәпләрдә, мәктәпләрдә***
***Белер өчен бик күпне,***
***Яратырга китапны.***
***Өйрәтәләр мәктәпләрдә, мәктәпләрдә***

3. *Таңнар ничек атканны,*
*Кояш ничек батканны.*
*Аңлаталар мәктәпләрдә,мәктәпләрдә*
*Табарга утрауларны,*
*Биек – биек тауларны.*
*Өйрәтәләр мәктәпләрдә, мәктәпләрдә*
*Табарга утрауларны,*
*Биек – биек тауларны.*
*Өйрәтәләр мәктәпләрдә, мәктәпләрдә*

*4. Өтер белән noктаны,*
*Кайчан – кайда куйганны.*
*Өйрәтәләр мәктәпләрдә, мәктәпләрдә*
*Дуслык кадерен белергә,*
*Сузылсын дип гомергә.*
*Өйрәтәләр мәктәпләрдә, мәктәпләрдә*
*Дуслык кадерен белергә,*
*Сузылсын дип гомергә.*
*Өйрәтәләр мәктәпләрдә, мәктәпләрдә*

effects1.ru